Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Күлле-Киме авыл җирлеге Советы Карары

26 август 2019 ел

№ 103

Күлле-Киме авыл җирлеге Советының 2018 елның 15 декаберендәге 86 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын уздыру тәртибе турында» Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

2019 елның 1 апрелендәге 87-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында»гы законнын 1 статьясындагы 13 пунктчасының б пунктчасы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының «Күлле-Киме авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Күлле-Киме авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Күлле-Киме авыл җирлеге Советының 2018 елның 15 декаберендәге 83 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге территориясендә гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында» Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::
1.1. Әлеге Нигезләмәнең 3.5 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:
«3.5. Гражданнар җыены анда катнашуда торак пункт яки җирлектә сайлау хокукына ия булган кешеләрнең яртысыннан артыгы катнашкан очракта хокуклы. Торак пунктта әлеге торак пунктта сайлау хокукына ия кешеләрнең яртысыннан артык бер үк вакытта бергә булу мөмкинлеге булмаса, күрсәтелгән торак пункт кергән муниципаль берәмлек уставы нигезендә гражданнар җыены гражданнар җыенын үткәрү турында Карар кабул ителгән көннән бер айдан да артмый торган вакытка этаплап уздырыла. Шул ук вакытта элек гражданнар Җыенында катнашкан затлар тавыш бирүдә киләсе этапларда катнашмый. Җыенда катнашучыларның яртысыннан артыгы әгәр аның өчен тавыш биргән булса, Гражданнар җыены карары кабул ителгән дип санала.»

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Әтнә муниципаль районының Интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб –адресы буенча) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: (pravo.tatarstan.ru веб – адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Әтнә муниципаль районы
Күлле-Киме авыл җирлеге башлыгы

Х.Х.Гәрәев